ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ГОРОДА НИЖНЕКАМСКА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

пр. Строителей, д. 12, г. Нижнекамск, 423570

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ТҮБӘН КАМА ШӘҺӘРЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Төзүчеләр пр., 12-нче йорт, Түбән Кама шәһәре, 423570

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

31 03 2021 г. № 78

Татарстан Республикасы Түбән Кама шәһәре муниципаль берәмлеге буенча 2021 елның II кварталына торак урыны гомуми мәйданының бер квадрат метрына уртача базар бәясен раслау турында

Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетының 2020 елның 22 маендагы 322 номерлы карары белән расланган «Түбән Кама муниципаль районында яшь гаиләләрне торак белән тәэмин итү» программасы кысаларында аларга күрсәтелгән түләүләр федераль бюджет акчалары исәбеннән торак урыннары сатып алу (төзү) өчен бирелә торган торак шартларын яхшыртуга мохтаҗлар буларак исәпкә куелган яшь гаиләләр өчен социаль түләүләр күләмен исәпләү максатларында, Россия Федерациясе Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгының 2021 елның 26 февралендәге 94/пр номерлы «2021 елның икенче кварталына Россия Федерациясе субъектлары буенча торак урыны гомуми мәйданының бер квадрат метрының уртача базар бәясе күрсәткечләре турында» боерыгына таянып, карар бирәм:

1. 2021 елның II кварталына Түбән Кама шәһәре муниципаль берәмлеге буенча торак урыны гомуми мәйданының бер квадрат метрына уртача базар бәясен 55 914 (илле биш мең тугыз йөз ундүрт) сум күләмендә расларга.

2. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Түбән Кама шәһәре башкарма комитетының торак сәясәте бүлеге башлыгы Е.С. Митрошенковага йөкләргә.

Җитәкче А.Р. Салаватов